| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ КАРАР**

2024 елның 4 октябре № 24

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 14 нче номерлы карарына (15.10.2018 № 29, 29.11.2018 № 34, 01.03.2023 № 5, 10.04.2023 № 15 үзгәрешләр белән)үзгәрешләр кертү хакында

1. Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

2. 2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 1 августындагы 23 номерлы карарын (15.10.2018 ел, № 29, 29.11.2018 № 34, 01.03.2023 № 5, 10.04.2023 № 15 үзгәрешләр белән)үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 14 номерлы карарына (15.10.2018 № 29, 29.11.2018 № 34, 01.03.2023 № 5, 10.04.2023 № 15 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктның 1 пунктчасындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук салым салу объектларында урнашкан гаражларның һәм машина урыннарының кадастр бәясе аларның һәрберсенә 300 миллион сумнан артык»;

б) карарның 2 пунктындагы 1 пунктчасының 4 абзацын төшереп калдырырга;

в) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектлары исемлегенә кертелгән салым салу объектларына карата 2025-2027 еллар салым чорларына 1,2 процент һәм 2028 елдан башлап алдагы салым чорларына 2 процент салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган;

Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2025 елга 2 процент һәм 2026 елдан башлап алдагы салым чорына 2,5 процент.».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан җирлекнең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, Совет урамы, 98 йорт, Совет урамы, 103 йорт, Карагай авылы, Тельман урамы, 31 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Советы рәисе

Г.Ә.Әхмәтова